КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 август г.Казань № 702

«2024 – 2026 елларга чит илдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында

Чит илдә яшәүче ватандашларыбызның ирекле күченүе хисабына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый һәм демографик үсешенә ярдәм итү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Чит илдә яшәүче ватандашларыбызны Россия Федерациясенә ирекле күчерүгә ярдәм итү чаралары турында» 2006 елның 22 июнендәге 637 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «2024 –2026 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын дәүләт программасын гамәлгә ашыру һәм аны үтәү барышын тикшереп тору өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.

3. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык

күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1189 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чит илдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән расланган «Чит илдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 17 апрель, 259 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чит илдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 26 апрель, 344 нче карары белән расланган «Чит илдә яшәүче ватандашларыбызның Татарстан Республикасына ирекле күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 04 июль, 504 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин